КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 11 гыйнвар г.Казань № 2

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турында» 2010 ел, 7 июнь, 433 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 22 октябрь, 842 нче; 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче; 2013 ел, 20 апрель, 272 нче; 2017 ел, 2 август, 539 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче пунктта «630,1» саннарын «659,4» саннарына алыштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 сентябрь, 759 нчы; 2013 ел, 20 апрель, 272 нче; 2013 ел, 3 июль, 468 нче; 2013 ел, 18 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 647 нче; 2017 ел, 2 август, 539 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктка «республика» сүзен «төбәк» сүзенә, «күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган махсуслаштырылган оешмалар (алга таба – төбәк операторы)» сүзләрен «төбәк операторлары» сүзләренә алыштырырга;

2.1 нче һәм 3.7 нче пунктларда «республика» сүзен «төбәк» сүзенә алыштырырга;

3.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Инспекция үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – гражданнарның торакка хокукларын тәэмин итү һәм кулланучыларга сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.01 <*>);

Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән – социаль-икътисадый программалар эшләү функциясен гамәлгә ашырганда (01.01 <*>);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар эшләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01 <*>);

республика башкарма хакимият органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03 <*>);

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән – мәгълүматлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15 <*>);

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән – бюджет процессы (Татарстан Республикасы һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджеты) белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02.1 <*>);

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән – хезмәт белән билгеләнгән тәртиптә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13 <*>);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән – Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01.03 <*>);

муниципаль торак тикшерүендә тоту органнары белән – «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 ел, 10 октябрь, ТРЗ-72 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә;

Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 1.1 өлешендә билгеләнгән вәкаләтләр бирелгән җирле үзидарә органнары белән – төзелә торган килешүләр нигезендә;

күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә үз эшчәнлекләрен үзләре җайга сала торган оешмалар яки күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге юридик затларның яки индивидуаль эшмәкәрләрнең башка берләшмәләре белән – килешүләр нигезендә;

---

<*> Кодны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча билгеләү

торак милекчеләре ширкәтләре, торак, торак-төзелеш һәм башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары берләшмәләре (ассоциацияләре, берлекләре) белән – килешүләр нигезендә.»;

3.6 нчы пунктның «а» пунктчасында:

егерменче абзацта «коммерциягә карамаган махсуслаштырылган оешмалар» сүзләрен «төбәк операторлары» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җайланмасыннан файдаланганда һәм аны карап тотканда куркынычсызлыкны тәэмин итү чаралары турында» 2013 ел, 14 май, 410 нчы карары белән расланган Газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәткәндә йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җайланмасыннан файдаланганда һәм аны карап тотканда куркынычсызлыкны тәэмин итү өлешендә газны куллану кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган махсуслаштырылган оешма белән йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җайланмасына техник хезмәт күрсәтү һәм аны ремонтлау турындагы шартнамә булу-булмауга;

инвалидлар өчен махсус чаралар белән җиһазландырылган күпфатирлы йортлар урыннарыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә»;

4.2 нче пунктның унҗиденче абзацында «күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган махсуслаштырылган оешмаларга (төбәк операторы)» дигән сүзләрне «төбәк операторына» дигән сүзләргә алыштырырга.

3. Бу карардагы 1 нче пунктның гамәле 2017 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин